ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02 июнь 2023 ел № 4673

Башкарма комитетның 2020 елның 15 июнендәге 2848 номерлы карары белән расланган «2020-2025 елларга «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2020 елның 15 июнендәге 2848 номерлы карары (Башкарма комитетның 2021 елның 20 октябрендәге 6902 номерлы, 2021 елның 13 декабрендәге 8098 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган «2020-2025 елларга «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасының 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 пунктта 1 пунктчада «(әлеге Кагыйдәләргә 1 нче кушымта»)» сүзләреннән соң «(яшәү урыны буенча район хакимиятенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә)» сүзләрен өстәргә;

2) 16 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Күрсәтелгән документлар яшәү урыны буенча район хакимиятенә шәхсән мөрәҗәгать итү юлы белән яки «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба - Бердәм портал) аша электрон формада тапшырыла. Документлар электрон формада тапшырылган очракта, документлар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткәндә файдалану рөхсәт ителә торган электрон имза төрләре турында» 2012 елның 25 июнендәге 634 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткәндә файдалану рөхсәт ителә торган электрон имза төрләрен билгеләү кагыйдәләренең 2.1 пункты нигезендә, яшь гаилә әгъзасының гади электрон имзасы белән имзалана.»;

3) 17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Торакны үстерү бүлеге әлеге Кагыйдәләрнең 14, 15 пунктларында каралган документлардагы мәгълүматларны тикшерү буенча эшне оештыра һәм, әлеге документлар тапшырылган көннән башлап 5 эш көне эчендә, яшь гаиләне чарада катнашучы дип тану турында яисә танудан баш тарту турында карар кабул итә.»;

4) 18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Яшь гаиләгә кабул ителгән карар турында язмача яки Бердәм портал аша электрон формада, торакны үстерү бүлеге тарафыннан 3 эш көне эчендә хәбәр ителә.»;

5) 31 пункттагы икенче абзацка түбәндәге эчтәлектәге җөмлә өстәргә:

«Социаль түләү алу хокукы турында бирелгән таныклыкны алмаштыру турында гариза, язма формада яки Бердәм портал аша электрон формада, әлеге таныклыкны биргән район хакимиятенә тапшырыла.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары А.С. Ганиевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов